Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Советы

**КАРАР № XXXVIII -6**

Балык Бистәсе штп.

2023 елның 25 мае

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2021 елның 31 августындагы №XI-3 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатыннан, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы №1-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2021 елның 31 августындагы №XI-3 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәгә (05.03.2022 №XX-6 редакциясендә) (алга таба-Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

нигезләмә тексты буенча «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы — Р.Р. Ислямов